РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

***Постановление*** ***Карар***

07.05.2026 **Чистай ш.** № 73

Чистай шәһәр Башкарма комитетының «Чистай шәһәре территориясендә вак ваклап сату сәүдә челтәренең стационар булмаган сәүдә объектларын һәм вакытлыча җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 27 июнендәге 139 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 29 маендагы 108-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, муниципаль хокукый актны Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай шәһәр Башкарма комитетының «Чистай шәһәре территориясендә вак ваклап сату сәүдә челтәренең стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануының вакытлыча объектларын урнаштыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 27 июнендәге 139 номерлы карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Чистай шәһәре территориясендә вак ваклап сату сәүдә челтәренең стационар булмаган сәүдә объектларын һәм вакытлыча җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру турындагы 4.14 пунктының өченче абзацын (1 нче кушымта) төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карар басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Шәһәр Башкарма комитеты
җитәкчесе А. Р. Хаматов